*Рәсимә Галиева,*

*филология фәннәре кандидаты,*

*Казан федераль университеты доценты*

# Флорид Әгъзамов – фельетончы

Татар журналистикасы тарихында теория һәм практиканы бәйләп, бергә үреп, тыгыз эшчәнлек алып барган шәхесләр сирәк. Шуларның берсе – Флорид Әгъзамов. Ул журналистикадан белем бирүче остаз гына түгел, матбугатның төрле өлкәсендә эшләгән чын журналист иде. Без бүген аны очеркист, тәрҗемә итү остасы буларак кына түгел, чын мәгънәсендә фельетончы буларак та билгеләп үтәргә тиешбез.

Әдәби-публицистик жанр кысаларында сатира жанрлары - фельетон, памфлет, мәзәк һ.б. - өйрәнелә. Жанр таләпләрен күбрәк белү теләге Флорид Әгъзамов кебек фельетоннар язарга да этәрсә, димәк, башкара торган эшеңнең нәтиҗәсе бар дигән сүз. Киңкырлы иҗатының бер юнәлеше булып аның фельетоннары тора, дип әйтергә тулы хакыбыз бар. Тормыш тәҗрибесе туплаган, теге яки бу проблемага үз фикере булган автор шул елларның, шул көннәрнең әһәмиятле вакыйгаларын кузгата. Нинди дә булса проблеманы чишәргә алына. Язылган фельетоннарның көче дә аның укучыга, язмада күрсәтелгән объетка тәэсирендә чагыла.

Фельетоннарны ул Ф. Бикмәтле псевдонимы аша укучыларына тәкъдим итә. Бикмәт ул авторның туган авылы, Башкортстанның Чакмагыш районы җирлегендә урнашкан. Заманында галим Илдар Низамов «Бикмәтленең сүзе хикмәтле» исеме белән язма бастырган иде. Ул анда Флорид Әгъзамовны «укыту, өйрәтү эшен иң оста башкаручы ул — үзе уйнаучы тренер» дип билгеләп үткән иде. Фельетоннары хакында «Бу әсәрләрендә студентларга,

яшь журналистларга гына түгел, азау ярган каләмдәшләргә дә ярап куярдай осталык чалымнары булырга тиеш. Аларның нидән гыйбарәт икәнлеген анализлау белгечләр эше. Өйрәнергә, кулланырга иде; бер тәҗрибә, бер талант та аяк астында ятмаска тиеш, ә фельетончыныкы бигрәк тә...», - дип яза ул. Галим Илдар Низамов язмасы 1996 елда язылган, инде 15 ел вакыт үтеп киткән. Бүген исә үзгәртеп кору елларындагы фельетоннарны анализлаганда без нигездә Ф. Әгъзамов иҗатына тукталабыз. Аның әле дә актуальлеген югалтмаган иҗат әсәрләрен укып, өйрәнәбез.

Әдәби-публицистик жанрлардан сатира жанрының гаҗәеп үрнәген үз мисалында раслады ул. «Мәгърифәт» газетасының һәр санында диярлек чыгып барган фельетоннары нәкъ менә фельетон жанры таләпләренә буйсынган, көн кадагына куелган темаларны күтәргән иде. XX гасыр башында шундый сатирик жанр үрнәкләре белән без «Уклар», «Карчыга», «Ялт-йолт», «Яшен» сатирик журналлары аша танышкан булсак, соңрак «Вакыт», «Казан мөхбире», «Чаян», «Кызыл Татарстан» басмаларында хәтта махсус фельетон язучылар, оста танылган фельетончылар булган. Илдәге сәясәт, җәмгыятьтәге сүз ирегенең булу-булмавы да жанрларның яшәешенә нык тәэсир итэ. Кайбер жанрлар кулланылыштан төшеп калды, фельетон да берникадәр үз позициясен югалтты.

Сатира жанрларының иң әйдәп баручысы, төп жанрларның берсе булган фельетонга кыскача аңлатма бирсәк, французчадан кәгазъ бите дип тәрҗемә ителә. Иҗтимагый тормыштагы тискәре күренешләрдән көлүче газета мәкаләсенең бер төре санала. «Фельетон Франциядә барлыкка килә һәм башта ул театр, әдәбият мәсьәләләренә багышланган тәнкыйть мәкаләләренең исеме буларак кулланыла. Хәзерге вакытта фельтьон яки кечкенә фельетон дип тормыштагы, аерым кешеләрнең эшчәнлегендәге зарарлы яки кимчелекле якларны үткен рәвештә тәнкыйть итүче сатирик мәкаләләрне атыйлар» [2, б. 185].

Фельетонның килеп чыгышы, жанр мәсьәләсе хакында М.Э. Виленский болай дип язып үтә: «Кайбер белгечләр беренче фельетон 1800 елның 28

гыйнваренда «Журнал де деба» дигән француз газетасында барлыкка килгән дип саный. Газетаның подвал өлеше фельетон дип аталган, аны кисеп алырга мөмкин булган. Газеталар шулай итеп фельетонсыз һәм фельетон белән сатылган. Беренче фельетоннарда белдерүләр, театр афишасы һәм башкалар басылган. Соңга таба үткен телле театр рецензияләре барлыкка килә башлый. Аларның авторы Жоффуруа исемле журналист була. Аның рецензияләре бүген дә фельетон таләпләренә туры килә» [3, с. 97].

Татар журналистикасында сатирик жанрларга нигез салучы Габдулла Тукай да көн кадагына суга торган темалар хакындагы беренче язмаларын матбугат битләренә җибәргәндә, фельетон җибәрәм, дип әйтә торган булган. Фельетон турында төгәл генә аңлатма юк, һәрбер автор анны үзенчә билгели. Вакыт үтү белән фельетон жанры да, үзгәреш кичереп кенә калмыйча, яшәүдән да туктады.

«Вакытлар узу белән фельетон сүзе бер төрле текстларга карата гына кулланыла башлады. М.Е. Салтыков-Щедрин, В.М. Дорошевич, А.В. Амфитеатров, М.Е. Кольцов, И.А. Ильиф һәм Е.П. Петров, С.Д. Нариньяни, Э.Я. Пархомовский кебек фельетонистлар рус журналистикасын югарылыкка күтәрделәр. Совет чоры журналитикасында фельетон аерым урын алып тора. Үзгәртеп кору еллары жанрны яшәүдән туктатты. Моның сәбәпләре жанр үзенчәлекләренә дә бәйле. Фельетон нинди дә булса явызлыкны фаш итә бит. Озак еллар дәвамында матбугат моңарчы үзе көлгән, үзе фаш иткән объектларга бәйле булып калды. Матбугат чараларының гамәлгә куючылары үзгәрде. Дәүләт дотациясендәге газеталар акчалы шәхси кулларга күчте. Сәясәттәге тотрыксызлык та жанр таләпләренә йогынты ясады. Җәмгыять тормышында тотрыклылык, мораль ориентирлар урнашу белән фельетон үз позициясен ныгытачак» [4, с. 268], -  ди Мәскәү профессоры А.А. Тертычный.

Татар журналистикасында сатирик жанрлар формалашуы һәм үсеше иң беренче чиратта Г. Тукай иҗаты белән бәйле, дидек. Ф. Әгъзамов та аның беренче чиратта фельетон остасы булуына басым ясый: «Г. Тукай – беренче

чиратта фельетон остасы. Аның фельетоннарында гомерен кичергән иҗтимагый мөнәсәбәтләр; социаль типлар, күренешләр, фактлар, сыйфатлар көлке чаралары белән адәм мәсхәрәсе ителә, фаш кылына. Аларда әдәби һәм публицистик, образ һәм логик фикерләү чаралары бергә кушыла» [1,6. 256].

Фельетон жанрында иҗат иту өчен белем дә, тәҗрибә дә, тел чараларын файдалану да кирәк. Ә сатира жанрлары теориясен яхшы белгән, бер үк вакытта көндәлек газетада эшләп килгән, димәк, каләме нык чарланган һәм чорны яхшы күзаллаган Флорид Әгъзамовның фельетоннары һәркемгә үрнәк булырлык. «Кайгынамә караламасы», «Экономика экономияле булырга тиеш», «Кызым, сиңа әйтәм...», «Икетеллелек, или двуязычие», «Кешенең үрдәге дә...», «Аллергия», «Мөгез чыгару», «Ташкабакчылык», «Иске чикмән», «Түгәрәкләнү», «Түгәрәк өстәл», «Адашу» кебек фельетоннары бүген дә актуальлеген югалтмый. Аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең тормышчан, дәвамлы булуы бераз уйландыра да. Әлбәттә, 1995 - 1996 еллар авазы сизелә аларда, бу шулай булырга тиеш тә. «Кызым, сиңа әйтәм...» фельетонында берничә ай дәвамында укытучылары акча алмаган, бу мәсьәләне берничек тә хәл итә алмыйча Түрә Түрәевич, Чин Чинычлар янына йөрүче мәктәп директоры хакында сүз бара. Бүген замана мәктәбендә акча да бар, ләкин бу системада әле фельетон итеп язарлык темалар бик күп. Димәк, теманы дәвам итергә була. Шул ук «Икетеллелек, или двуязычие» фельетонының язылышы ук күп мәсьәләләрне фаш итә. «Если ачуланмасагыз, икетеллелек турында язарга решать иттем әле», - дип башлый ул үзенең фельетонын. «Икетеллек дип – авыз чайкыбыз чайкавын, однако, ике телдә разговаривать итүчеләрнең берсенең дә авызын ачтырып караганыбыз юк. Мин предполагать итәмен, андый адәмнәрнең авыз куышлыгында ике тел булырга тиеш. Һич югында, олы тел белән беррәттән кече тел «телгә килмәгән» микән. Олы тел родной языкта сөйләшә, ә кечесе - чужой языкта. По-моему, бу - зур открытие булмагае». Шул тонда фельетон ахырга кадәр дәвам итә. Аннан күтәрелгән проблеманың да актуальлеге бәхәссез.

Кайсы гына сатирик әсәрен алсаң да, Ф. Әгъзамовның образлар белән оста эш итүенә гаҗәпләнәсең. Фельетоннарында көлке тудыруның әллә никадәр алымнарын очратырга була. Анаграмма, каламбур, герой исеме белән яңгырашлы яңа исем ясау, ирония, сарказм, гипербола, гротеск, литота, фараз кылу, фантастика, дини образлар һәм сюжетлар, пародия, эпитет, чагыштыру, сатирик монологларны аерып күрсәтергә була. Флорид абыйның язу стиле бик үзенчәлекле. Ул бер фельетон эчендә мөмкин булган бөтен тел-стиль чараларыннан мул файдалана. Халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итә. Мәкаль, әйтем, канатлы сүзләрне куп куллануы да язмаларын халыкчан итә. Фельетонның теле бу жанрда эшләүчегә күп мөмкинлекләр бирә. Мәсәлән, Флорид абыйга гына хас риторик җөмләләр куллану («Ник бик тиз эреп бетә торган гадәте бар икән бу акча дигән каһәрнең!», «Па-а-нимаешь, мин монда акча сугып утырам чту ли»), гади сөйләм сүзләрен файдалану (каһәр, вәссәләм, махы бирә, шайтан белсен, кырт кистем, таю ягын карадым һ.б.) осталыгы бар. Фельетоннарында сүрәтләүне кечәйтүче парлы сүзләрне күп бирелүе дә уңышлы: ай-һай, ит-май, кызыл-көрән, гап-гади, җап-җансыз, сап-салкын, әрҗә-әрҗә, җил-җил, савыт-саба, кызарынып-бүртенеп, ярсып-ярсып, шылтыр-шылтыр. Телнең бөтен лексик составы эшкә җигелә икән, димәк, бу авторның осталыгы турында сөйли. Флорид Әгъзамовның һәрбер фельетонына тукталып, һәрберсен тел-стиль җәһәтеннән анализларга мөмкин булыр иде. Тематикасын, проблематикасын, фельетон жанры таләпләрен ачыклау да аның никадәр үз укучысы өчен эшләгәнен күрсәтеп тора. Фельетончы заманында газетада үз укучысын тапса, бүген ул тагы да күбрәк файда китерә – студентларга белемнәрен арттыруда ярдәм итә. Озак еллар дәвамында укучыны көләргә дә, нәфрәтләнергә дә мәҗбүр иткән фельетонистның исеме озын гомерле булыр.

## Әдәбият


1. *Әгъзамов Ф.И.* Тукай -журналист / Ф.И. Әгъзамов. - Казан, 1986.- 256 с.
2. Әдәбият белеме сүзлеге / тез-ред. А.Г. Әхмәдуллин. - Казан: Татар, кит. нәшр., 1990. -238 б.
3. *Виленский М.Э.* Как написать фельетон / М.Э. Виленский. - М., 1958.
4. Тертычный А.А. Жанры периодической печати: учеб. Пособие /А.А. Тертычный. – М.: Аспект Пресс, 2000. – 268 с.